**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 декабря 2020 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 25 июня 2013 года № 52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 6 (II часть); 2014, № 5, № 11 (I часть); 2015, № 12 (I часть); 2016, № 1 – 2, № 10; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 33 (часть I), № 94 (часть I); 2018, № 38 (часть I); 2019, № 19 (часть I) следующие изменения:

1) в части 1 статьи 3:

а) в пункте 5 слова «сроком на три года с распределением по годам в пределах указанного срока» исключить;

б) в пункте 6 слова «сроком на три года с распределением по годам в пределах указанного срока» исключить;

2) в пункте 1 статьи 4 слова «сроком на три года с распределением по годам в пределах указанного срока» заменить словами «в соответствии с частью 4 статьи $10^1$ настоящего Закона»;

3) в части 2 статьи 9 после слов «собственнику такого помещения» дополнить словами «, и может быть дифференцирован в зависимости от муниципального образования, в котором расположен многоквартирный дом», слова «с учетом типа и этажности многоквартирного дома» заменить словами «с учетом его типа и этажности»;

4) в статье 10:

а) наименование после слов «Порядок подготовки» дополнить словом «, актуализации»;

б) часть 9 дополнить словами «в соответствии с порядком, утвержденным Кабинетом Министров Республики Татарстан»;

в) части 11 и $11^1$ признать утратившими силу;

5) дополнить статьей $10^1$ следующего содержания:

«Статья $10^1$. **Порядок формирования и утверждения краткосрочных планов реализации региональной программы капитального ремонта**

1. В целях реализации региональной программы капитального ремонта, конкретизации сроков проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, уточнения планируемых видов услуг и (или) работ по капитальному ремонту общего имущества в многоквартирных домах, определения видов и объема государственной поддержки, муниципальной поддержки капитального ремонта Кабинет Министров Республики Татарстан утверждает краткосрочные планы реализации региональной программы капитального ремонта в установленном им порядке.

2. Краткосрочные планы реализации региональной программы капитального ремонта утверждаются сроком на три года с распределением по годам в пределах указанного срока.

3. Краткосрочные планы реализации региональной программы капитального ремонта формируются исходя из принципов:

1) использования на цели капитального ремонта остатков средств на счете, счетах регионального оператора, не использованных в предшествующем году, и прогнозируемого объема поступлений взносов на капитальный ремонт в текущем году с учетом требований, установленных статьей 185 Жилищного кодекса Российской Федерации;

2) необходимости корректировки объема работ по капитальному ремонту общего имущества в многоквартирных домах исходя из фактического уровня собираемости средств на капитальный ремонт на счете, счетах регионального оператора;

3) актуализации в связи с проведением в порядке, предусмотренном частью 6 статьи 189 Жилищного кодекса Российской Федерации, капитального ремонта многоквартирного дома в объеме, необходимом для ликвидации последствий аварии, иной чрезвычайной ситуации природного или техногенного характера.

4. Органы местного самоуправления утверждают краткосрочные планы реализации региональной программы капитального ремонта в случае, если это предусмотрено нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан, в порядке, установленном этим нормативным правовым актом.

5. Краткосрочные планы реализации региональной программы капитального ремонта подлежат размещению в государственной информационной системе жилищно-коммунального хозяйства Кабинетом Министров Республики Татарстан

или органом местного самоуправления, утвердившими соответствующий краткосрочный план, в соответствии с частью 8 статьи 168 Жилищного кодекса Российской Федерации.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
25 декабря 2020 года
№ 89-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешендә:
а) 5 пунктта «өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп,» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 6 пунктта «өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 4 статьяның 1 пунктында «өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп,» сүзләрен «әлеге Законның $10^1$ статьясындагы 4 өлеше нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 9 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме күпфатирлы йорттагы урын милекчесенә карый торган урынның гомуми мәйданыннан чыгып билгеләнә һәм, күпфатирлы йортның төрен һәм ничә катлы булуын, аның төзелеш конструкцияләренең аерым элементларына һәм инженерлык системаларына капиталь ремонт ясау хакын, чираттагы капиталь ремонт ясаганчы алардан нәтиҗәле файдалануның норматив срокларын (ремонтара норматив сроклар), шулай

ук күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча Россия Федерациясе Торак кодексында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында билгеләнгән эшләр исемлеген исәпкә алып, күпфатирлы йорт урнашкан муниципаль берәмлеккә карап дифференциацияләнергә мөмкин.»;

4) 10 статьяда:

а) исемендә «программа әзерләү» сүзләреннән соң «, актуальләштерү» сүзен өстәргә;

б) 9 өлештә «региональ программа» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган тәртип нигезендә» сүзләрен өстәргә;

в) 11 һәм $11^1$ өлешләрне үз көчләрен югалткан дип танырга;

5) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ статья өстәргә:

«$10^1$ статья. **Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын төзү һәм раслау тәртибе**

1. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең планлаштырыла торган төрләрен төгәлләштерү, капиталь ремонтка дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзе билгеләгән тәртиптә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслый.

2. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнары өч еллык срокка, күрсәтелгән срок чикләрендә елларга бүлеп, раслана.

3. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнары түбәндәге принциплардан чыгып төзелә:

1) Россия Федерациясе Торак кодексының 185 статьясында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, региональ оператор счетындагы, счетларындагы алдагы елда файдаланылмый калган акчаларны һәм агымдагы елда капиталь ремонт өчен кертемнәр керүнең фаразланган күләмен капиталь ремонт максатларына тоту;

2) региональ оператор счетында, счетларында капиталь ремонт өчен акча җыелуның факттагы дәрәҗәсеннән чыгып, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча эшләр күләмен төзәтү кирәклеге;

3) Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 6 өлешендә каралган тәртиптә күпфатирлы йортка авариядән, башка табигый яисә техноген характердагы гадәттән тыш хәлдән соңгы зыяннарны бетерү өчен кирәкле булган күләмдә капиталь ремонт ясауга бәйле рәвештә актуальләштерү.

4. Җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актында каралган очракта, шушы норматив хокукый актта билгеләнгән тәртиптә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслыйлар.

5. Капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнары Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 8 өлеше нигезендә тиешле кыска сроклы планны раслаган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә җирле үзидарә органы тарафыннан торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасына урнаштырылырга тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОТДЕЛ ОБЩИЙ

Казан, Кремль
2020 ел, 25 декабрь
№ 89-ТРЗ